КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 12 июль г.Казань № 567

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 ел, 17 декабрь, 542 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 22 гыйнвар, 22 нче; 2005 ел, 30 май, 239 нчы; 2006 ел, 2 октябрь, 490 нчы; 2007 ел, 6 апрель, 123 нче; 2008 ел, 8 сентябрь, 640 нчы; 2010 ел, 29 ноябрь, 956 нчы; 2011 ел, 21 июнь, 496 нчы; 2011 ел, 6 декабрь, 1001 нче; 2012 ел, 13 апрель, 304 нче; 2013 ел, 19 гыйнвар, 20 нче; 2013 ел, 12 март, 157 нче; 2014 ел, 8 февраль, 80 нче; 2014 ел, 5 декабрь, 947 нче; 2015 ел, 15 апрель, 254 нче; 2015 ел, 1 декабрь, 911 нче; 2016 ел, 22 июнь, 425 нче; 2016 ел, 10 сентябрь, 625 нче; 2016 ел, 20 декабрь, 959 нчы; 2017 ел, 10 май, 268 нче; 2017 ел, 28 август, 604 нче; 2017 ел, 27 октябрь, 812 нче; 2017 ел, 1 ноябрь, 833 нче; 2018 ел, 25 декабрь, 1228 нче; 2019 ел, 7 март, 163 нче; 2019 ел, 5 август, 644 нче; 2019 ел, 10 декабрь, 1131 нче; 2020 ел, 2 июнь, 461 нче; 2020 ел, 11 сентябрь, 827 нче; 2020 ел, 5 ноябрь, 999 нчы; 2020 ел, 16 декабрь, 1141 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Ай саен бирелә торган акчалата түләү билгеләү өчен бу Нигезләмәнең 2.1 пунктында күрсәтелгән гражданнар, аларның законлы вәкилләре яки алар тарафыннан ышанычнамә нигезендә вәкаләт бирелгән затлар яшәү урыны буенча Үзәк бүлегенә түбәндәгеләрне тапшыра:

имза укый торган электрон җайланмалар ярдәмендә кул куеп була торган ай саен бирелә торган акчалата түләү билгеләү турында гариза (алга таба – гариза);

затның бу Нигезләмәнең 2.1 пунктында күрсәтелгән гражданнар категорияләренә каравын раслый торган документлар күчермәләрен;

әгәр ай саен бирелә торган акчалата түләү билгеләү өчен гариза бу Нигезләмәнең 2.1 пунктында күрсәтелгән гражданның ышанычлы заты тарафыннан бирелсә, Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә (алга таба – ышанычнамә) күчермәсен.

Хезмәт ветераннары бу Нигезләмәнең кушымтасындагы 1 пунктның өченче абзацында һәм 2 пунктның бишенче һәм тугызынчы абзацларында күрсәтелгән керемнәрне раслый торган документларны (әлеге керемнәр булганда) өстәмә рәвештә тапшыра.

Бу Нигезләмәнең 2.1 пунктында күрсәтелгән гражданнар, аларның законлы вәкилләре яки алар тарафыннан шанычнамә нигезендә вәкаләт бирелгән затлар гариза белән мөрәҗәгать иткәндә гариза бирүченең шәхесен раслый торган документын күрсәтә һәм банкта яки башка кредит оешмасында ачылган шәхси счет реквизитларын тапшыра.

2018 елның 31 декабре хәленә карата «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнарында каралган пенсия билгеләү шартларына туры килә торган, әмма 60 һәм 55 яше (шул ук эзлеклелектә ир-атлар һәм хатын-кызлар) тулмаган хезмәт ветераннары, 2018 елның 31 декабре хәленә карата «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнарында каралган пенсия билгеләү шартларына туры килә торган, «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законы белән гамәлгә куелган Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән затлар 2018 елның 31 декабре хәленә карата үзләренең әлеге федераль законнарда каралган пенсия билгеләү шартларына туры килүе турында Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлегеннән белешмә кәгазен өстәмә рәвештә тапшыра.»;

2.5 пунктта:

беренче абзацка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Ай саен бирелә торган акчалата түләү билгеләү турында йә билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү срогы, ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында рәсми соратыла торган мәгълүмат бирелмәгән очракта, 20 эш көненә озайтыла.»;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ай саен бирелә торган акчалата түләү билгеләүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«бу Нигезләмәнең 2.2 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау;

хезмәт ветеранының уртача айлык кереме 20 мең сумнан артып китү;

хезмәт ветеранының бу Нигезләмә кушымтасында төрләр исемлеге күрсәтелгән керемнәре булмау;

бу Нигезләмәнең 2.1 пунктында күрсәтелгән гражданнарның Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча ай саен бирелә торган акчалата түләү билгеләү өчен мөрәҗәгать иткән көннән 90 көн эчендә җайга салынмаган бурычы булу.»;

2.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.8. Хезмәт ветеранына ай саен бирелә торган акчалата түләү билгеләү өчен уртача айлык керем, барлык кирәкле документлар белән бергә, ай саен бирелә торган акчалата түләү билгеләү турында гариза бирелгән айга кадәрге соңгы алты календарь айга (алга таба – исәп-хисап чоры) билгеләнә.»;

түбәндәге эчтәлекле $2.10^1$ пункт өстәргә:

«$2.10^1$. Хезмәт ветеранының ризалыгы булганда ай саен бирелә торган акчалата түләү билгеләү физик затларның Федераль салым хезмәтендәге ай саен бирелә торган акчалата түләү билгеләү өчен мөрәҗәгать иткән айга кадәрге 12 айның соңгы алты аена керемнәре турында мәгълүмат нигезендә башкарыла.»;

3.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6. Балага ай саен бирелә торган пособие билгеләү өчен бу Нигезләмәнең 3.1 пунктында күрсәтелгән гражданнар яки алар тарафыннан ышанычнамә нигезендә вәкаләт бирелгән затлар бала белән бергә яши торган ата-ананың (законлы вәкилнең) яшәү урыны буенча Үзәк бүлегенә түбәндәгеләрне тапшыра:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча, банкта яки башка кредит оешмасында ачылган шәхси счет реквизитларын күрсәтеп, балага ай саен бирелә торган пособие билгеләү турында гариза (балага ай саен бирелә торган пособиене банк яки башка кредит оешмасы аша алганда);

гариза бирүченең һәм аның гаилә әгъзаларының Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балага айлык пособие билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача керемен исәпләү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 ел, 17 декабрь, 542 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2016 ел, 10 сентябрь, 625 нче карары белән расланган Балага айлык пособие билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача керемен исәпләү тәртибенең 2.1 пунктындагы «к» пунктчасының өченче абзацында һәм 2.2 пунктындагы «в» пунктчасының алтынчы абзацында күрсәтелгән керемнәрен раслый торган документларны;

гаилә әгъзалары милкендә булган, Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында хокуклары теркәлмәгән күчемсез мөлкәт объектларына хокук билгели торган документлар күчермәләрен;

чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан бирелгән бала тууны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык һәм аның нотариаль таныкланган рус теленә тәрҗемәсе күчермәләрен (булганда);

Россия Федерациясеннән читтә гомуми белем бирү оешмасында белем алучы 16 яшьтән олырак бала өчен чит ил дәүләте территориясендә бирелгән уку турында документ һәм аның нотариаль таныкланган рус теленә тәрҗемәсе күчермәсен;

әгәр бу Нигезләмәнең 3.1 пунктында күрсәтелгән гражданнар гаиләсе составына Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган исемлектә күрсәтелгән хроник авыруның авыр формасыннан интегүче затлар кергән очракта һәм законнар нигезендә алар белән бергә яшәү мөмкин булмаса, гаилә әгъзасының бу Нигезләмәнең 3.1 пунктында күрсәтелгән гражданнар гаиләсе составына Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган исемлектә күрсәтелгән һәм законнар нигезендә алар белән бергә яшәргә мөмкинлек бирми торган хроник авыруы булу турында белешмә кәгазен;

балага ай саен бирелә торган пособие билгеләү өчен гариза ышанычлы зат тарафыннан тапшырылган очракта, ышанычлы затлар өчен ышанычнамә.

Документларның күчермәләре Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган очракта, алар төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырыла һәм Үзәк бүлеге белгече тарафыннан таныклана.»;

3.11 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«яшәү урыны буенча гариза бирүче белән бергә теркәлгән гражданнар турында мәгълүмат»;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16 яшьтән олырак баланың гомуми белем бирү оешмасында укуы турында мәгълүмат.»;

3.13 пунктның беренче абзацына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Балага ай саен бирелә торган пособие билгеләү турында йә билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү срогы, ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында рәсми соратыла торган мәгълүмат бирелмәгән очракта, 20 эш көненә озайтыла.»;

3.17 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«гаиләнең җан башына уртача кереме күләме Татарстан Республикасында балага ай саен бирелә торган пособие билгеләү өчен мөрәҗәгать иткән датага билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән артып китү;

гариза бирүченең яки аның эшкә сәләтле гаилә әгъзаларының керемнәре булмау (18 яшькә кадәрге биш һәм аннан күбрәк баласы булган күп балалы гаиләнең бердәнбер атасын йә анасын яисә ата-анасыннан берсенең кереме булмаган очрактан тыш (ата-ананың берсе хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру, йә пенсионер, йә инвалид бала (яки I төркем инвалид, яки дәвалау учреждениесенең бәяләмәсе буенча даими рәвештә чит кеше каравына мохтаҗ йә 80 яше тулган карт кеше) карауны гамәлгә ашыручы, йә билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган зат булу шарты белән)).»;

4.1 һәм 4.2 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Өч һәм аннан күбрәк балалы (тәрбиягә алган балаларны кертеп) гаиләдән 6 яшькә кадәрге балага дару чаралары сатып алу өчен субсидия бала (балалар) белән бергә фактта яши торган ата-анага (законлы вәкилгә) билгеләнә.

4.2. Бу Нигезләмәнең 4.1 пунктында күрсәтелгән гражданнар яки алар тарафыннан ышанычнамә нигезендә вәкаләт бирелгән затлар дару чаралары сатып алуга субсидия билгеләү өчен яшәү урыны буенча Үзәк бүлегенә түбәндәгеләрне тапшыра:

дару чаралары сатып алуга субсидия билгеләү турында гариза;

чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан бирелгән бала тууны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык һәм аның нотариаль танықланган рус теленә тәрҗемәсе күчермәләрен (булганда);

әгәр дару чаралары сатып алуга субсидия билгеләү өчен гариза ышанычлы зат тарафыннан тапшырылса, ышанычнамә күчермәсен.

Документларның күчермәләре Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә танықланмаган очракта, алар төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырыла һәм Үзәк бүлеге белгече тарафыннан танықлана.»;

4.3 пунктта «гариза бирүченең гаилә составы турында мәгълүмат» сүзләрен «яшәү урыны буенча гариза бирүче белән бергә теркәлгән гражданнар турында мәгълүмат» сүзләренә алмаштырырга;

4.5 пунктның беренче абзацына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Дару чаралары сатып алуга субсидия билгеләү турында йә билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү срогы, ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында рәсми соратыла торган мәгълүмат бирелмәгән очракта, 20 эш көненә озайтыла.»;

5.1 һәм 5.2 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Өч һәм аннан да күбрәк балалы (тәрбиягә алынган балаларны кертеп) гаиләләрдән гомуми белем бирү оешмалары укучыларына һәм һөнәри белем бирү оешмалары студентларына транспортта йөрү өчен ай саен бирелә торган субсидия (алга таба – транспортта йөрү өчен ай саен бирелә торган субсидия) бала (балалар) белән бергә фактта яши торган ата-анага (законлы вәкилгә) билгеләнә.

5.2. Бу Нигезләмәнең 5.1 пунктында күрсәтелгән гражданнар яки алар тарафыннан ышанычнамә нигезендә вәкаләт бирелгән затлар транспортта йөрү өчен ай саен бирелә торган субсидия билгеләү өчен яшәү урыны буенча Үзәк бүлегенә түбәндәгеләрне тапшыра:

транспортта йөрү өчен ай саен бирелә торган субсидия билгеләү турында гариза;

чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан бирелгән бала тууны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык һәм аның нотариаль танықланган рус теленә тәрҗемәсе күчермәләрен (булганда);

чыгарылыш датасын күрсәтеп, чит ил дәүләте территориясендә бирелгән Россия Федерациясеннән читтә уку турында документның һәм аның нотариаль танықланган рус теленә тәрҗемәсе күчермәләрен (ел саен уку елы башында тапшырыла);

транспортта йөрү өчен ай саен бирелә торган субсидия билгеләү өчен гариза ышанычлы зат тарафыннан тапшырылса, ышанычнамә күчермәсен.

Документларның күчермәләре Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә танықланмаган очракта, алар төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырыла һәм Үзәк бүлеге белгече тарафыннан танықлана.»;

5.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.3. Үзәк бүлеге ведомствоара соратулар нигезендә, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасыннан файдаланып, электрон рәвештә түбәндәге мәгълүматны ала:

яшәү урыны буенча гариза бирүче белән бергә теркәлгән гражданнар турында;

баланы тәрбиягә алучы гаиләгә тапшыру турында;

чыгарылыш датасын күрсәтеп, баланың гомуми белем бирү оешмасында, һөнәри белем бирү оешмасында укуы турында;

балаларның тууын дәүләт теркәвенә алу турында;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурыч булу (булмау) турында.»;

5.5 пунктның беренче абзацына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Транспортта йөрү өчен субсидия билгеләү турында йә билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү срогы, ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында рәсми соратыла торган мәгълүмат бирелмәгән очракта, 20 эш көненә озайтыла.»;

6.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.5. Транспортта йөрү өчен субсидия, укуны тәмамлаганда бер тапкыр бирелә торган акчалата пособие, укуны тәмамлаганда өс киеме, аяк киеме, йомшак инвентарь һәм җиһаз комплекты сатып алуга бер тапкыр бирелә торган пособие, уку әдәбиятын һәм язу кирәк-яраклары сатып алуга ел саен бирелә торган пособие, өс киеме, аяк киеме һәм йомшак инвентарь комплекты сатып алуга ел саен бирелә торган пособие, ай саен бирелә торган стипендия, туклануга ай саен бирелә торган пособие алу өчен аларны алучылар, аларның законлы вәкилләре яисә алар тарафыннан ышанычнамә нигезендә вәкаләт бирелгән затлар (алга таба – гариза бирүчеләр) белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешманың урнашу урыны буенча яисә опекунның (химаячененң) яки алучының яшәү урыны буенча Үзәк бүлегенә, банкта яки башка кредит оешмасында ачылган шәхси счет реквизитларын (банк яки башка кредит оешмасы аша субсидияләр, стипендияләр, пособиеләр алганда) күрсәтеп, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча гариза тапшыра.

Укуны тәмамлаганда бер тапкыр бирелә торган пособие, укуны тәмамлаганда өс киеме, аяк киеме, йомшак инвентарь һәм җиһаз комплекты сатып алуга бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү турындагы гаризаны гариза бирүчеләр уку тәмамланган көннән 30 календарь көн эчендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешманың урнашу урыны буенча яисә опекунның (химаячененң) яки алучының яшәү урыны буенча Үзәк бүлегенә тапшыра.

Законлы вәкилләр (законнарда каралган очракларда) йә алучы тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар аларның алучы мәнфәгатьләрен яклауга вәкаләтләрен раслый торган документлар күчермәләрен өстәмә рәвештә тапшыра.

Уку чорында атасы белән анасын яки ике бердәнбер атасын йә анасын югалткан затлар чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан бирелгән ата-ананың үлеме турындагы документ күчермәсен һәм аның нотариаль таныкланган рус теленә тәрҗемәсе күчермәсен өстәмә рәвештә тапшыра.

Документларның күчермәләре Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган очракта, алар төп нөсхәләре күрсәтелеп тапшырыла һәм Үзәк бүлеге белгече тарафыннан таныклана.

Гариза белән мөрәҗәгать иткәндә гариза бирүчеләр шәхесне таныклый торган документын күрсәтә, банкта ачылган шәхси счет реквизитларын бирә.»;

6.6 пунктта:

өченче абзацта «Татарстан Республикасы территориясендәге мәгариф оешмасыннан» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«белем алуга (укуны тәмамлауга) бәйле рәвештә, белем бирү оешмасыннан чыгару датасы турында;

уку чорында атасы белән анасын яки бердәнбер атасын йә анасын югалткан затларга субсидия, стипендия, пособие билгеләү өчен ата-ананың үлеме турында.»;

6.8 пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Транспортта йөрү өчен субсидия билгеләү турында йә билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү срогы, ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында рәсми соратыла торган мәгълүмат бирелмәгән очракта, 20 эш көненә озайтыла.»;

6.10 пунктта «уку тәмамланган көннән бер ай эчендә билгеләнә һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

6.15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.15. Транспортта йөрү өчен субсидия, укуны тәмамлаганда бер тапкыр бирелә торган акчалата пособие, укуны тәмамлаганда өс киеме, аяк киеме, йомшак инвентарь һәм җиһаз комплекты сатып алуга бер тапкыр бирелә торган пособие, уку әдәбиятын һәм язу кирәк-яраклары сатып алуга ел саен бирелә торган пособие, өс киеме, аяк киеме һәм йомшак инвентарь комплекты сатып алуга ел саен бирелә торган пособие, ай саен бирелә торган стипендия, туклануга ай саен бирелә торган пособие билгеләүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

бу Нигезләмәнең 6.5 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау;

укуны тәмамлаганда бер тапкыр бирелә торган пособие, укуны тәмамлаганда өс киеме, аяк киеме, йомшак инвентарь һәм җиһаз комплекты сатып алуга бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү өчен гариза бирүче бу Нигезләмәнең 6.5 пунктындагы икенче абзацында билгеләнгән сроктан соңрак мөрәҗәгать итү.»;

7.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.2. Элемтә хезмәтләре күрсәтүгә субсидия алу өчен бу Нигезләмәнең

7.1 пунктында күрсәтелгән гражданнар, аларның законлы вәкилләре яки алар тарафыннан ышанычнамә нигезендә вәкаләт бирелгән затлар яшәү урыны буенча Үзәк бүлегенә түбәндәгеләрне тапшыра:

элемтә хезмәтләре күрсәтүгә субсидия билгеләү турында гариза;

затның бу Нигезләмәнең 7.1 пунктында күрсәтелгән гражданнар категорияләренә каравын раслый торган документлар күчермәләрен;

элемтә хезмәтләре күрсәтүгә субсидия билгеләү өчен гариза ышанычлы зат тарафыннан тапшырылса, ышанычнамә күчермәсен.

Хезмәт ветераннары бу Нигезләмәнең кушымтасындагы 1 пунктның өченче абзацында һәм 2 пунктның бишенче һәм тугызынчы абзацларында күрсәтелгән керемнәрне раслый торган документларны (әлеге керемнәр булганда) өстәмә рәвештә тапшыра.

Документларның күчермәләре Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә танылканмаган очракта, алар төп нөсхәләре күрсәтелеп тапшырыла һәм Үзәк бүлеге белгече тарафыннан таныклана.

Бу Нигезләмәнең 7.1 пунктында күрсәтелгән гражданнар, аларның законлы вәкилләре яки алар тарафыннан ышанычнамә нигезендә вәкаләт бирелгән затлар гариза белән мөрәҗәгать иткәндә гариза бирүченең шәхесен раслый торган документны

күрсәтә, банкта яки башка кредит учреждениесендә ачылган шәхси счет реквизитларын тапшыра.

2018 елның 31 декабре хәленә карата «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнарында каралган пенсия билгеләү шартларына туры килә торган, әмма 60 һәм 55 яше (шул ук эзлеклелектә ир-атлар һәм хатын-кызлар) тулмаган хезмәт ветераннары, 2018 елның 31 декабре хәленә карата «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнарында каралган пенсия билгеләү шартларына туры килә торган, «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законы белән гамәлгә куелган Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән затлар Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлегеннән 2018 елның 31 декабре хәленә карата үзләренең әлеге федераль законнарда каралган пенсия билгеләү шартларына туры килүе турында белешмә кәгазен өстәмә рәвештә тапшыра.»;

7.6 пунктта:

беренче абзацка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Элемтә хезмәтләре күрсәтүгә субсидия билгеләү турында йә билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү срогы, ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында рәсми соратыла торган мәгълүмат бирелмәгән очракта, 20 эш көненә озайтыла.»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«хезмәт ветеранының бу Нигезләмә кушымтасында төрләр исемлеге күрсәтелгән керемнәре булмау.»;

9.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9.1. Транспортта йөрү өчен ай саен бирелә торган акчалата түләү билгеләү өчен «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнары нигезендә пенсия билгәләнгән пенсионерлар, 60 һәм 55 яше (шул ук эзлеклелектә ир-атлар һәм хатын-кызлар) тулган гражданнар, 2018 елның 31 декабре хәленә карата федераль законнарда каралган пенсия билгеләү шартларына туры килә торган, әмма 60 һәм 55 яше (шул ук эзлеклелектә ир-атлар һәм хатын-кызлар) тулмаган, Татарстан Республикасында яшәүче, уртача айлык керем күләме мөрәҗәгать иткән датага 20 мең сумнан артмаган һәм мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының кушымтасында билгеләнгән гаиләнең (гражданның) мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсеннән түбән булган, Россия Федерациясенең һәм (яки) Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары буенча социаль ярдәм чараларына хокукы булмаган гражданнар (алга таба – пенсионерлар) яки аларның законлы вәкилләре, яки алар тарафыннан ышанычнамә нигезендә вәкаләт бирелгән затлар (алга таба – гариза бирүчеләр) яшәү урыны буенча Үзәк бүлегенә түбәндәгеләрне тапшыра:

транспортта йөрү өчен ай саен бирелә торган акчалата түләү билгеләү турында гариза;

транспортта йөрү өчен ай саен бирелә торган акчалата түләү билгеләү өчен гариза ышанычлы зат тарафыннан тапшырылса, ышанычнамә күчермәсен.

23 яшьтән кечерәк гариза бирүче урта һөнәри һәм югары белем бирә торган мәгариф оешмасында укыган очракта, стипендия алмау факты турында документ күчермәсен;

бу Нигезләмәнең кушымтасындагы 1 пунктның өченче абзацында һәм 2 пунктның бишенче һәм тугызынчы абзацларында күрсәтелгән керемнәрне раслый торган документларны (әлеге керемнәр булганда) тапшыра;

пенсионер милкендә булган, Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында хокуклары теркәлмәгән күчемсез мөлкәт объектларына хокук билгели торган документлар күчермәләрен.

Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган исемлектә күрсәтелгән хроник авыруның авыр формасыннан интегүче пенсионерлар, законнар нигезендә алар белән бергә яшәү мөмкин булмаган очракта, мондый авыруның булуы турында белешмә кәгазен өстәмә рәвештә тапшыра.

Документларның күчермәләре Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган очракта, алар төп нөсхәләре күрсәтелеп тапшырыла һәм Үзәк бүлеге белгече тарафыннан таныклана.

Гариза белән мөрәҗәгать иткәндә гариза бирүчеләр шәхесне таныклый торган документын күрсәтә, банкта яки башка кредит учреждениесендә ачылган шәхси счет реквизитларын бирә.

2018 елның 31 декабре хәленә карата «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнарында каралган пенсия билгеләү шартларына туры килә торган, әмма 60 һәм 55 яше тулмаган (шул ук эзлеклелектә ир-атлар һәм хатын-кызлар) Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлегеннән 2018 елның 31 декабре хәленә карата аларның әлеге федераль законнарда каралган пенсия билгеләү шартларына туры килүе турында белешмә кәгазен өстәмә рәвештә тапшыра.»;

9.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9.4. Бу Нигезләмәнең 9.1 пунктында күрсәтелгән, тапшырылган документларга һәм бу Нигезләмәнең 9.2, 9.11 пунктларында күрсәтелгән мәгълүматка нигезләнеп, Үзәк бүлеге барлык кирәкле документлар белән бергә транспортта йөрү өчен ай саен бирелә торган акчалата түләү билгеләү турында гариза теркәлгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә транспортта йөрү өчен ай саен бирелә торган акчалата түләү билгеләү турында яки билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм гариза бирүчегә тиешле карар турында гариза бирүче тарафыннан гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта адресы буенча язма формада, электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә, телефонга смс-хәбәр итеп, «Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» Татарстан Республикасы дәүләт информацион системасында шәхси кабинет аша) хәбәр итә. Транспортта йөрү өчен ай саен бирелә торган акчалата түләү билгеләү турында йә билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү срогы, ведомствоара хезмәттәш-

лек кысаларында рәсми соратыла торган мәгълүмат бирелмәгән очракта, 20 эш көненә озайтыла.

Ай саен бирелә торган акчалата түләү билгеләүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

бу Нигезләмәнең 9.1 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау;

бу Нигезләмәнең 9.1 нче пунктында күрсәтелгән гражданнарның Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булу;

гариза бирүчеләрнең (гомуми белем бирелә торган мәгариф оешмаларында, урта һөнәри һәм югары белем бирелә торган мәгариф оешмаларында көндезге уку формасында белем алучы 23 яшьтән кечерәк гариза бирүчеләрдән тыш) бу Нигезләмә кушымтасында төрләр исемлеге күрсәтелгән керемнәре булмау;

гариза бирүченең уртача айлык кереме күләме 20 мең сумнан артып китү;

гариза бирүченең мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кушымтасының «а» – «г», «е», «ж» пунктларында билгеләнгән мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсеннән артып китү;

9.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9.8. Транспортта йөрү өчен ай саен бирелә торган акчалата түләү билгеләү өчен уртача айлык керем, барлык кирәкле документларны теркәп, транспортта йөрү өчен ай саен бирелә торган акчалата түләү билгеләү турында гариза бирелгән айга кадәрге соңгы алты календарь айга (алга таба – исәп-хисап чоры) билгеләнә.»;

түбәндәге эчтәлекле $9.10^{1}$ пункт өстәргә:

«$9.10^{1}$. Гражданның ризалыгы булганда транспортта йөрү өчен ай саен бирелә торган акчалата түләү билгеләү физик затларның Федераль салым хезмәтендәге транспортта йөрү өчен ай саен бирелә торган акчалата түләү билгеләү өчен мөрәҗәгать иткән айга кадәрге 12 айның соңгы алты аена керемнәре турында мәгълүмат нигезендә башкарыла.»;

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү турында» 2006 ел, 24 март, 126 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 3 июнь, 370 нче; 2009 ел, 6 апрель, 203 нче; 2012 ел, 23 февраль, 153 нче; 2013 ел, 12 март, 157 нче; 2014 ел, 25 август, 611 нче; 2015 ел, 23 сентябрь, 701 нче; 2015 ел, 1 декабрь, 911 нче; 2016 ел, 22 июнь, 425 нче; 2016 ел, 26 декабрь, 998 нче; 2018 ел, 25 декабрь, 1228 нче; 2019 ел, 11 март, 168 нче; 2019 ел, 13 март, 181 нче; 2019 ел, 20 декабрь, 1173 нче; 2020 ел, 2 июнь, 461 нче; 2020 ел, 5 ноябрь, 999 нчы; 2020 ел, 16 декабрь, 1141 нче; 2021 ел, 20 февраль, 92 нче; 2021 ел, 10 май, 322 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктта «бүлекләре» сүзеннән соң «(алга таба – Үзәк бүлеге)» сүзләрен өстәргә;

2.2 пунктта:

беренче абзацта «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге бүлеге» сүзләрен «Үзәк бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Хезмәт ветераннары бу Нигезләмәнең кушымтасындагы 1 пунктның өченче абзацында һәм 2 пунктның бишенче һәм тугызынчы абзацларында күрсәтелгән керемнәрне раслый торган документларны (әлеге керемнәр булганда) өстәмә рәвештә тапшыра.»;

2.3 пунктта:

җиденче абзацка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Ташлама-субсидия билгеләү турында яисә билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү срогы, ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында рәсми соратыла торган мәгълүмат бирелмәгән очракта, 20 эш көненә озайтыла.»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Ташлама-субсидия билгеләүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

хезмәт ветеранының уртача айлык кереме 20 мең сумнан артып китү;

хезмәт ветеранының бу Нигезләмә кушымтасында төрләр исемлеге күрсәтелгән керемнәре булмау;

бу Нигезләмәнең 2.1 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән гражданнарның Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча ташлама-субсидия билгеләү өчен мөрәҗәгать иткән көннән 90 көн эчендә җайга салынмаган бурычы булу;

бу Нигезләмәнең 2.2 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау.»;

$2.3^1$ пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$2.3^1$. Хезмәт ветеранына ташлама-субсидия билгеләү өчен уртача айлык керем барлык кирәкле документлар белән бергә ташлама-субсидия билгеләү турында гариза бирелгән айга кадәрге соңгы алты календарь айга (алга таба – исәп-хисап чоры) билгеләнә.»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Гражданның ризалыгы булганда хезмәт ветеранына ташлама-субсидия билгеләү физик затларның Федераль салым хезмәтендәге ташлама-субсидия билгеләү өчен мөрәҗәгать иткән айга кадәрге 12 айның соңгы алты аена керемнәре турында мәгълүмат нигезендә башкарыла.»;

2.5 пунктның икенче абзацында «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге бүлекләре» сүзләрен «Үзәк бүлекләре» сүзләренә алмаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшьтән җиде яшькә кадәрге (җиде яшьне кертеп) балага айлык акчалата түләү турында» 2020 ел, 10 апрель, 267 нче карары белән расланган Өч яшьтән җиде яшькә кадәрге (җиде яшьне кертеп) балага айлык акчалата түләү бирү тәртибенә һәм шартларына үзгәреш кертү хакында» 2021 ел, 23 апрель, 275 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Бу карар (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшьтән җиде яшькә кадәрге (җиде яшьне кертеп) балага айлык акчалата түләү турында» 2020 ел, 10 апрель, 267 нче карары белән расланган Өч яшьтән җиде яшькә кадәрге (җиде яшьне кертеп) балага айлык акчалата түләү бирү тәртибенең һәм шартларының (бу карар редакциясендәге) 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 2.3 пунктындагы унсигезенче, егерме сигезенче һәм утыз икенче абзацларыннан һәм 2.6 пунктындагы егерме икенче, утыз дүртенче һәм утыз бишенче абзацларыннан тыш) аңа кул куйган көннән үз көченә керә.»;

3 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшьтән җиде яшькә кадәрге (җиде яшьне кертеп) балага айлык акчалата түләү турында» 2020 ел, 10 апрель, 267 нче карары белән расланган Өч яшьтән җиде яшькә кадәрге (җиде яшьне кертеп) балага айлык акчалата түләү бирү тәртибенең һәм шартларының (бу карар редакциясендәге) 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 2.3 пунктындагы унсигезенче, егерме сигезенче һәм утыз икенче абзацларыннан һәм 2.6 пунктындагы егерме икенче, утыз дүртенче һәм утыз бишенче абзацларының нигезләмәләре 2022 елның 1 гыйнварына кадәр өч яшьтән җиде яшькә кадәрге (җиде яшьне кертеп) балага ай саен бирелә торган акчалата түләү билгеләнгән гражданнарга кагылмый;».

4. Бу карарның 1 пунктындагы унтугызынчы – егерме икенче, йөз унҗиденче – йөз егерменче абзацларының, 2 пунктындагы унбишенче – унтугызынчы абзацларының һәм 3 пунктының гамәле 2021 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин